**Кукмара муниципаль районы**
**Югары Чура авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

«20» декабрь, 2021 ел № 42

Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең 2022 нче елга һәм 2023 һәм 2024 нче елларның план чорына бюджеты турында

Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге башлыгы тәкъдим иткән Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең 2022 елга һәм 2023, 2024 елларның план чорына бюджет проектын карап, Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

**1 статья**

1. 2022 елга авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразланыла торган гомуми күләме 2 284,1 сум;

2) авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2 284,1 сум

3) авыл җирлеге бюджеты кытлыгы (профицит) 0 сум күләмендә.

2. 2023 елга һәм 2024 елга авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразланыла торган гомуми күләме 2023 елга 2 297,7 сум һәм 2024 елга 2 306,1 сум күләмендә;

2) Кукмара муниципаль районы бюджетының 2023 елга гомуми чыгымнары күләме 2 297,7 сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 2 297,7 сум һәм 2024 елга 2 306,1 сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 2 306,1 сум;

3) 2023 елга авыл җирлеге бюджеты кытлыгы (профициты) 0 сум, 2024 елга 0 сум күләмендә.

3. Авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын билгеләргә:

2022 елга әлеге Карарга 1 нче кушымта нигезендә;

2023 елга һәм 2024 елга әлеге Карарга 2 нче кушымта нигезендә.

**2 статья**

1. 2023 елның 1 гыйнварына торышы буенча билгеләргә:

авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль бурычның иң югары чиге ноль сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча ноль сум күләмендә.

2. 2024 елның 1 гыйнварына торышы буенча билгеләргә:

авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль бурычның иң югары чиге ноль сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча ноль сум күләмендә.

3. 2025 елның 1 гыйнварына торышы буенча билгеләргә:

авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль бурычның иң югары чиге ноль сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча ноль сум күләмендә.

**3 статья**

Авыл җирлеге бюджетында 2022 елгаавыл җирлеге бюджетының фаразланыла торган керем күләмен әлеге Карарга 3 нче кушымта нигезендә һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына әлеге Карарга 4 нче һәм 5 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

**4 статья**

2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлтелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен ноль сум күләмендә билгеләргә.

**5 статья**

Авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын расларга:

2022 елга әлеге Карарга 6 нчы кушымта нигезендә;

2023 елга әлеге Карарга 7 нче кушымта нигезендә;

2024 елга әлеге Карарга 8 нче кушымта нигезендә;

**6 статья**

Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге бюджетында Кукмара муниципаль районы бюджетыннан керә торган бюджетара трансфертларны 2022 нче елга 1 340,1 мең сум, 2023 нче елга 1 319,7 мең сум, 2024 нче елга 1 298,3 мең сум күләмендә исәпкә алырга, шул исәптән:

- муниципаль районнар бюджетларыннан бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр 2022 елга 1 194,4 мең сум, 2023 елга 1 169,0 мең сум, 2024 елга 1 142,2 мең сум күләмендә.

- хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр 2022 елга 145,7 мең сум, 2023 елга 150,7 мең сум, 2024 елга 156,1 мең сум.

**7 статья**

Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге Башкарма комитеты 2022 елда һәм 2023-2024 елларда муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

**8 статья**

Кукмара муниципаль районының Югары Чура авыл җирлеге бюджетыннан авыл җирлеге исеменнән товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар төзелгән өчен файдаланылмаган, әлеге муниципаль контрактларның шартлары нигезендә 2021 елда түләнергә тиешле бюджет ассигнованиеләренең калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә акча калдыклары, Югары Чура авыл җирлеге Башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, 2022 елда әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

**9 статья**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментының Кукмара муниципаль районы буенча территориаль бүлеге килешү нигезендә һәм түләүсез нигездә Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

**10 статья**

3. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**11 статья**

Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларына элү юлы белән халыкка игълан итәргә.

Кукмара муниципаль районы
Югары Чура авыл җирлеге
башлыгы /В.Н. Андреев/